**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

02.12.2025 1463-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясе турында» 2022 елның 17 мартындагы 197-п номерлы боерыгы (14.03.2023 ел, №263-п, 06.06.2023 ел, №695-п, 20.03.2025 ел, №291-п боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Клементьева Диана Юрьевнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгын;

Назаров Наил Госман улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгын.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 мартындагы 192-п номерлы боерыгы (31.08.2022 ел, №755-п, 14.03.2023

ел, №263-п, 06.06.2023 ел, №695-п, 11.09.2024 ел, №995-п боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан С.Т.Вахитовны чыгарырга.

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Клементьева Диана Юрьевнаны – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгын – җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия рәисе урынбасарын;

Назаров Наил Госман улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгын.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Тугушевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков